ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.05.2019 с. Верхний Услон 444

Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче
Һәм мәктәпкәчә, башлангыч гомуми,төп гомуми һәм
урта гомуми белем бирү программалары буенча белем
алырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе һәм
ата-аналар тарафыннан билгеләнгән белем алу
формалары турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 63 статьясы нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу, Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның һәр дәрәҗәдәге гомуми белем алуга хокукларын тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль белем бирү учреждениеләрендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. МКУ «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге»нә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештырырга.
3. Балаларны исәпкә алуны уздыруда катнашучы органнар, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә үз вәкаләтләре кысаларында МКУ «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» һәм мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны тормышка ашыруда белем бирү учреждениеләренә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны «ТР Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ Башлыгы В. В. Касыймовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе В.С. Тимиряев

Әзерләде:

Ф.Ф. Ахметова
3 нөсхәдә

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
№ 444, 16.05.2010 ел карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның ата - аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның ата - аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе Югары Ослан муниципаль районының мәгариф учреждениеләрендә төп белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны ел саен шәхси исәпкә алуны гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Конституциясенең 9 статьяның 1 өлешендәге 6 пункты, 63 статьяның 5 өлеше, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 № 273 - ФЗ Федераль законның 64 статьясындагы 3 өлеше нигезендә һәм гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга конституцион хокукларын үтәү максатларында эшләнгән.

1.3. Тәртип Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балалар исәбен оештыруны һәм Югары Ослан муниципаль районы территориясендә балаларны исәпкә алуны үткәрүдә катнашучы оешмалар белән билгеләнгән белем алу формаларын билгели.

1.4. Яшәү (тору) урыны буенча теркәлүгә карамастан, Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче (даими яки вакытлыча) яки булган балалар түбәндәге яшь чикләрендә белем алуга конституциячел хокукны гамәлгә ашыру максатларында исәпкә алынырга тиеш:

түбән чик-2 айдан кадәрге балалар;

югары чик-18 яшькә кадәрге балалар, шулай ук гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 18 яшьтән өлкәнрәк затлар.

1.5. Мәҗбүри гомуми белем алмаучы балаларны ачыклау һәм исәпкә алу, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләренең гамәлдәге законнар нигезендә кызыксынган затлар һәм оешмалар белән хезмәттәшлеге кысаларында гамәлгә ашырыла.

1.6. Мәгариф учреждениеләренең балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләре һәм органнары белән үзара хезмәттәшлеге буенча оештыру эшен МКУ «Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» үткәрә.

1.7. Балаларны исәпкә алу Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге учреждениеләре, оешмалары һәм структур бүлекчәләре белән үзара бәйләнештә алып барыла:

- мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләре;

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Югары Ослан муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе;

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге;

- «Үзәк район хастаханәсе» ДАСУ;

- РФ ЭЭМ ТР буенча муниципальара бүлегенең «Югары Ослан» полиция бүлеге;

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе.

1.8. Балаларны исәпкә алу буенча мәгълүмат әлеге Тәртип нигезендә «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп җыю, тапшыру, саклау һәм куллануга тапшырылырга тиеш.

2. Исәп мәгълүматларын формалаштыру.

2.1. Балаларны исәпкә алу «ЭДС» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәм «ТРда Электрон белем бирү» мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү буенча белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләрендә белем алырга тиешле балалар турында бердәм мәгълүмат банкын формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла (алга таба текст буенча- мәгълүматлар банкы).

2.2. Мәгълүматлар банкын формалаштырганда гражданнарның ризалыгы белән алынган шәхси мәгълүматлары, ә балигъ булмаган балаларга карата - аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән кулланыла. Гражданнарның шәхси мәгълүматларын исәпкә алу «Шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә башкарыла.

2.3. Мәгълүматлар банкын формалаштыру чыганаклары булып тора:

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә укырга кабул итүгә дәгъва кылучы балаларның электрон мәгълүматлар банкы - «ЭДС» АИС;

- «ТР Электрон мәгариф» ИС (электрон журнал).

2.4. Хисап мәгълүматларын формалаштырганда, МКУ «Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» Югары Ослан муниципаль районының учреждение һәм оешмаларыннан, структур бүлекчәләреннән алынган мәгълүматны исәпкә ала:

2.4.1. «Үзәк район хастаханәсе» ДАСУ мәгълүматлары:

- яшәү урыны буенча теркәлмәгән, әмма әлеге территориядә яшәүче, 6 яшь 6 айга җиткән һәм беренче классларга кабул ителергә тиешле балалар турында (сорау буенча)

- Югары Ослан муниципаль районы территориясенә 2 айдан 18 елга кадәр яңа килгән балалар турында (сорау буенча бирү вакыты)

2.4.2. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан бирелә торган белешмәләр:

- мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча укуны 2 айдан 7 елга кадәр тәгәлләүче һәм агымдагы елда беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турында мәгълүмат бирү вакыты ел саен 1 сентябрьгә, 1 мартка кадәр (кушымта формасы буенча);

- белем дәрәҗәсе һәм укыту формалары буенча укучылар саны, мәгълүмат бирү сроклары турында ел саен 01 сентябрь, 01 мартка кадәр (кушымта 2);

- тәрбияләнүчеләрнең, укучыларның саны турында гомуми җыелма мәгълүмат бирү вакыты ел саен 1 сентябрьгә, 1 мартка кадәр (3 нче кушымта).

- сәбәпсез уку дәресләренә йөрмәүче яки системалы рәвештә дәрес калдыручы укучылар турында, ай саен 1 числога мәгълүмат бирү вакыты (кушымта 4);

- ата-аналар (законлы вәкилләр) балаларны гаилә белеме һәм үз-үзеңә белем бирү рәвешендә белем алу рәвешләрен сайлап алу турында мәгълүмат бирү вакыты ел саен 1 сентябрьгә кадәр (5 нче кушымта).

2.4.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Югары Ослан муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе тарафыннан күрсәтелә торган белешмәләр:

Бердәм муниципаль мәгълүматлар банкында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдә теркәлгән балалар турында.

2.4.4. ТР буенча ЭЭМ муниципальара бүлегенең «Югары Ослан» полиция бүлеге мәгълүматлары:

- 18 яшькә кадәр иректән мәхрүм итү урыннарында хөкем ителгән һәм җәза үтәүче балалар турында,

- ябык типтагы махсус уку йортларында булган балалар турында.

2.5. Әлеге Тәртипнең 2.4.3-2.4.4 пунктында санап үтелгән балалар турында мәгълүматлар балалар турында шәхси мәгълүматларны үз эченә алган исемлекләр белән рәсмиләштерелә.

2.6. Белешмәләр, әлеге тәртипнең п. 2.5. күрсәтелгән МКУ «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» белән электрон рәвештә хезмәттәшлек итә торган оешма җитәкчеләре тарафыннан бирелә.

3. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның ата - аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештыру

3.1. МКУ «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге»

3.1.1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче 2 айдан 18 яшькә кадәрге балаларны исәпкә алуны оештыру эшен координацияли.

3.1.2. Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләреннән, Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә «ЭДС» (алга таба - «ЭДС» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша) белем алу хокукына ия балалар саны турында мәгълүматлар алу юлы белән исәпкә алуны гамәлгә ашыра.

3.1.3. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә укырга керү өчен исәпкә куелган балалар саны турында объектив мәгълүмат алу максатында , шулай ук агымдагы уку елында учреждениедә урын бирүгә мохтаҗ балалар саны (актуаль сорау) һәм аннан

соңгы елларда (кичектерелгән сорау), МКУ «Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» «Мәктәпкәчә белем бирү» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын (электрон чират) куллана.

3.1.4. Исәпкә алу балалар бакчаларына кабул итү процедурасының "үтәкүренмәлелеген" тәэмин итү, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, учреждениеләрдә урынның тиешле һәм җитәрлек күләмдә булуын тәэмин итүне планлаштыру, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларны карау максатыннан башкарыла. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә урын мондый урынга ихтыяҗ турында гаризалар керү чиратына карап бирелә. Федераль законнар белән гражданнарның аерым категорияләре өчен балаларны чираттан тыш һәм беренче чиратта мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урыннар белән тәэмин итүгә хокуклар билгеләнә.

3.1.5. Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем алуның төрле рәвешләрендә укучы балалар исәбен формалаштыра: оешмада һәм оешмадан читтә (гаилә белеме һәм үз-үзеңә белем бирү рәвешендә), шулай ук башка белем бирү учреждениеләренә күчерүгә мохтаҗ балалар.

3.1.6. Балаларны (яңа урынга күчүгә, мәгариф траекториясен төгәлләштерүгә, яисә башка шартларга бәйле рәвештә) күчерү бер мәгариф учреждениесеннән буш урыннар булган башка белем бирү учреждениесенә бирелә. Элегрәк бала укыган мәгариф учреждениесе белән белем бирү мөнәсәбәтләре, белем бирү программасын үзләштерүне дәвам итү өчен, башка учреждениеләргә күчерү нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 61 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә, ата-аналар (законлы вәкилләр) инициативасы белән туктатыла.

Әгәр ата-аналар (законлы вәкилләр) баланың бер мәгариф учреждениесендә укуын туктату турында карар кабул итсә дә, баланы күчерү тәртибендә түләүсез урыннары булмаган белем бирү учреждениесе табылмаса, укучы белем бирү учреждениесеннән, ә ата-аналар (законлы вәкилләр) 29.12.2012 № 273 Федераль законның 67 статьясындагы 4 өлеше нигезендә күчерелә

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә Мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча белем бирү учреждениесенә урын бирүгә мохтаҗ буларак әлеге баланы теркәүне дәвам итү өчен баланы урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен мөрәҗәгать итә.

3.1.7. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу рәвешләре исәбен алып бара.

3.1.8. Ата-аналар (законлы вәкилләре) балаларны гаилә белеме формасында мәктәпкәчә белем алу рәвешләрен сайлаганда ата-аналар (законлы вәкилләр) бу хакта «ЭДС» АИС аша «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ хәбәр итә. Күрсәтелгән балалар мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениесендә урын бирүгә мохтаҗ булган чираттагы исәпкә алынмый һәм электрон чираттан төшереп калдырылмый.

3.1.9. Ата-аналар (законлы вәкилләре) мәктәпкәчә белем бирүне гаилә белеме формасында алуны тәэмин итә торган балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) түләү алмыйча методик, психологик-педагогик, диагностик һәм консультатив ярдәм алырга хокуклы, шул исәптән тиешле консультация үзәкләре

булдырылган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә. Мондый төр ярдәм күрсәтүне тәэмин итү Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.1.10. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары һәм ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнгән белем алу формалары буенча укырга тиешле балалар исәбен гамәлгә ашыра.

3.1.11. 3.1.2.-3.1.8 п. күрсәтелгән мәгълүматны анализлау нәтиҗәләре буенча Югары Ослан муниципаль районы хакимиятенең мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрен Югары Ослан муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетү турындагы карары проектын эшли.

3.1.12. Ата-аналар (законлы вәкилләр) балаларны башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу рәвешләрен сайлаганда, ата-аналар (законлы вәкилләр) бу хакта МКУ «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» хәбәр итә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) балаларны сайлап алу турында мәгълүмат белем алу рәвешләре әлеге карар кушымтасына ярашлы таблицага кертелә (2 Кушымта).

3.2.Мәгариф учреждениесендә гомуми белем алмаган балаларны урнаштыру буенча чаралар күрә.

3.3. Белем бирү учреждениесе:

3.3.1. Әлеге тәртипнең . п. 2.3. нигезендә аларның яшәү урыннарына карамастан, учреждениедә тәрбияләнүчеләрне һәм укучыларны агымдагы исәпкә алуны оештыра һәм гамәлгә ашыра (теркәү үткәрә), МКУ «Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге»нә мәгълүмат бирә.

3.3.2. Мәгариф учреждениесендә дәресләрне сәбәпсез калдыручы яки системалы рәвештә дәрес калдыручы укучыларның исәбен алып бара.

3.3.3. Үз балаларын тәрбияләү һәм укыту буенча үз вазыйфаларын тиешенчә башкармаган гаиләләр ачыкланган очракта:

- балигъ булмаганнарның укуын оештыру өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) белән үзара хезмәттәшлек итү чараларын кичекмәстән кабул итә;
- гамәлдәге законнар нигезендә йогынты чаралары күрү өчен Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясенә хәбәр итә;
- МКУ «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге»нә ачыкланган һәм күрсәтелгән балалар өчен белем бирүне оештыру буенча кабул ителгән чаралар турында хәбәр итә (белем бирү учреждениесе, кабул итү датасы, класс, укыту формасы).

3.3.4. Гамәлдәге законнар нигезендә балаларны агымдагы исәпкә алу буенча МКУ «Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге»нә җибәрелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

3.3.5. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле 2 айдан 18 яшькә кадәрге балаларны исәпкә алу системасын камилләштерү турындагы тәкъдимнәрне «Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» муниципаль мәгариф учреждениесенә кертергә хокуклы.

1 нче кушымта

2 айдан 7 яшькә кадәр балалар турында,шулай ук мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча укуны тәмамлап чыгучылар һәм агымдагы елда беренче сыйныфка кабул ителергә тиеш балалар турында мәгълүмат

2 айдан 18 яшькә кадәр ачыкланган.- ФИО	Туу датасы	1 нче сыйныфка, балалар бакчасына (яки мәктәп классы, балалар бакчасы) планлаштырылган керү елы)	Кайсы мәктәптә, балалар бакчасында укырга планлаштыра (анда инде укый, тәрбияләнә)	Ата-анасы ФИО	0-18 яшьтән ачыкланган прописка адресы	0-18 яшьтән ачыкланган яшәү адресы

2 нче кушымта

Белем дәрәҗәсе укыту формалары һәм белем алу формалары буенча укучылар саны турында мәгълүмат

0 яшьтән 18 яшькә кадәр ачыкланган.- ФИО	Укыту формасы һәм белем алу формасы	Туу датасы	1 нче сыйныфка, балалар бакчасына (яки мәктәп классы, балалар бакчасы) планлаштырылган керү елы)	Кайсы мәктәптә, балалар бакчасында укырга планлаштыра (анда инде укый, тәрбияләнә)	Ата-анасы ФИО	0-18 яшьтән ачыкланган прописка адресы	0-18 яшьтән ачыкланган яшәү адресы

3 нче кушымта

Мәгариф оешмаларында белем дәрәҗәсе буенча тәрбияләнүчеләр, укучылар саны турында җыелма мәгълүмат

№	Исеме		
1	Мәгълүматлар банкында гомуми балалар саны		
2	Банктан киткән мәгълүматлар саны (сәбәбе)		
3	Банкка килгән мәгълүматлар саны (сәбәбе)		
4	МКДОУ да тәрбияләнүчеләр саны		
5	1-11 нче сыйныф укучылары саны		
6	Инвалид балалар саны		
7	Хисап датасына 1нче сыйныфка керүчеләр саны		
8	Хисап датасына чыгарылыш сыйныф укучылары саны		

4 нче кушымта

Сәбәпсез дәресләргә йөрмәүче яки системалы рәвештә дәрес калдыручы укучылар турында мәгълүматлар

№	Баланың Ф.И.О.	Туу датасы	Гомуми белем бирү оешмасы, класс	Яшәү урыны (булу) буенча теркәлү

5 нче кушымта

Ата-аналар (законлы вәкилләр) балаларны гаилә белеме һәм үз-үзеңә белем бирү рәвешендә белем алу рәвешләрен сайлап алу турында мәгълүмат

№	Укыту формасы һәм белем алу формасы	Ата-анасы ФИО (законлы вәкил)	Укучының ФИО	Укучының туу датасы	Балигъ булмаган балалар укыган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме	Агымдагы уку елында арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен сайлап алынган гомуми белем бирү учреждениесен ең исеме